**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлегә сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

Аксубай районының Түбән Савруш авылындагы Яшьләр урамы;

Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Коммунальная, Елга аръягы урамнары;

Кама Тамагы районы Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогының Парк урамы;

Кукмара районының Югары Кумор авылындагы Бакча урамы;

Зәй районы Бура-Киртә авылы янындагы «Зәй» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясе.

2. Түбәндәгеләр үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 2 октябрендәге ПУ-954 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1053 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 20 гыйнвар
№ ПУ-39